Р. З. Хәйдәрова, Г. М. Әхмәтҗанова,
Л. Ә. Гыйниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ

Укытучылар өчен методик кулланма

7



«Татармультфильм»

Р. З. Хәйдәрова, Г. М. Әхмәтҗанова,
Л. Ә. Гыйниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ

## 7 нче сыйныф

**Укытучылар өчен методик кулланма**

*Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан тәкъдим ителә*

Казан
2025

УДК 81.432.3-99(=411.2)я72
ББК 811.512.145(073.5)
Х18

Фәнни редакторы
**Р. З. Хәйдәрова,** педагогика фәннәре кандидаты, доцент

*Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всего издания или его части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

**Хайдарова, Р. З. и др.**
Х18 Государственный (татарский) язык Республики Татарстан: Татар теле. 7 класс: : методическое пособие для учителя к учебнику для общеобразовательных организаций основного общего образования (для обучающихся, не владеющих татарским языком) / Р. З. Хайдарова, Г. М. Ахметзянова, Л. А. Гиниятуллина. – Казань: Татармультфильм, 2025. – 36 с.

ISBN 978-5-906508-50-8

УДК 81.432.3-99(=411.2)я72
ББК 811.512.145(073.5)

ISBN 978-5-906508-50-8

© «Татармультфильм» нәшрияты, 2025
© Хәйдәрова Р. З., Әхмәтҗанова Г. М., Гыйниятуллина Л. Ә., 2025

## 7 нче сыйныфта «Татарстан Республикасы дәүләт (татар) теле» фәнен укыту өчен төзелгән «Татар теле» укыту-методик комплекты белән эшләү үзенчәлекләре

Федераль Дәүләт стандартларында белем бирү системасының төп үсеш юнәлеше – **системалы-эшчәнлекле юнәлеш (системно-деятельностный подход)**, ә системаны барлыкка китерә торган төп компонент – **нәтиҗә: шәхси, метапредмет, предмет нәтиҗәләре** дип билгеләнә. Стандартларда күрсәтелгән бу концептуаль методологик күрсәтмә рус телле балаларга татар теле укыту системасын оештыруның да нигезе булып тора.

Рус телендә сөйләшүче укучыларга татар телен дәүләт теле буларак укытуның төп максаты – укучыларның рухи һәм әхлакый үсешен тәэмин итү, аларның күпмилләтле җәмгыятьтә милләтара мөнәсәбәт культурасын формалаштыру, башка халыкларга карата хөрмәт хисе, мәдәниара диалогка осталык кебек универсаль күнекмәләр булдыру. Шулай ук татар телен дәүләт теле буларак укыту телне **аралашу чарасы** буларак үзләштерүне тәэмин итү, көндәлек тормышта, полиэтник җәмгыятьтә **үзара аңлашу** һәм **хезмәттәшлек итү** күнекмәләрен формалаштыру. Шулай ук укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерү, уку эшчәнлеген оештыруның нигезе булган универсаль уку гамәлләрен формалаштыру, аларны мөстәкыйль уку эшчәнлегенә әзерләү.

Татарстан Республикасы мәктәпләре өчен төп гомуми белем бирү баскычында татар теле фәнен укытуга **372 сәгать** вакыт бирелә. Базис укыту планында 7 нче сыйныфта атнага 3 сәгать исәбеннән **102 сәгать** каралган.

7 нче сыйныфта укучы рус телле балаларга тәкъдим ителгән укыту-методик комплекты (УМК) түбәндәге компонентлардан тора:

1. Дәреслек.
2. Укытучы өчен методик ярдәмлек:

– календарь-тематик план;
– ишетеп аңлау күнегүләре;
– контроль-үлчәм материаллары.

УМКга эчтәлек сайлау Россия мәгариф министрлыгының 18.05.2023 елгы 372 номерлы «Төп гомуми белем бирүнең федераль белем бирү программасын раслау турында»гы боерыгына (теркәлү вакыты: 12.07.2023 ел, №74229) һәм тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына нигезләнде**.**

**Телгә аралашу аша өйрәтү принцибының** нигезендә дәреслеккә сайланган эчтәлекнең укучыларның яшь үзенчәлекләренә, теләк-омтылышларына, аралашу ихтыяҗларына туры килүе мәҗбүр. Шушы психологик, педагогик таләпләр үтәлгәндә генә, уку материалын кабул итүдә укучыда актив фикри эшчәнлек башлана, үз фикерен әйтү теләге туа, укучы табигый рәвештә уку эшчәнлегенә тартыла.

Дәреслеккә түбәндәге аралашу темалары кертелде: «Белем һәм тормыш» («Мәктәп», «Яхшы уку серләре»), «Мин һәм минем яшьтәшләрем», «Буш вакыт» («Яраткан шөгыльләрем», «Сәяхәт итү», «Сәламәт яшәү рәвеше»), «Өлкәннәр һәм кечкенәләр», «Без Татарстанда яшибез», «Башкалабыз Казан» («Тарихи һәм истәлекле урыннар», «Татар халкының күренекле вәкилләре»).Тематик планнарда темаларның эчтәлеге киңәйтелеп, федераль эш программасына тәңгәллеге күрсәтеп барылды.

Федераль эш программасына нигезләнеп, дәреслеккә грамматик материал түбәндәгечә кертелде:

– хәзерге, үткән, киләчәк заман хикәя фигыль;

– охшату-чагыштыру рәвешләре (*тиз, акрын, әкрен*);

– күрсәтү (*бу, теге, шул, шундый*) һәм билгеләү *(барлык, бөтен, үз, һәр*) алмашлыклары;

– хәл фигыльнең *-гач (-гәч), -кач (-кәч)* формасы;

– җөмләнең баш кисәкләре; ия белән хәбәрнең ярашуы;

– гади фигыль хәбәрле җөмлә (*Мин татарча беләм*), исем хәбәрле җөмлә (*Безнең гаиләбез тату*) һәм кушма хәбәрле җөмлә (*Мин укырга яратам*);

– теркәгечләр: *һәм, да (дә), та (тә), яки*;

– кисәкчәләр*: гына (генә), кына (кенә);*

– әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре;

– кушма җөмләләр.

Моннан тыш, алдагы сыйныфларда өйрәнелгән лексик-грамматик материал даими рәвештә кабатланып барылды.

Рус телле балаларны татар сөйләменә коммуникатив технология нигезендә өйрәтү **дәреслекләренең төзелеше цикллылыкка** корылган. **Цикл – уку материалын диалогик, монологик, ягъни мөстәкыйль сөйләм дәрәҗәсенә җиткерү өчен кирәк булган дәресләр.** Ягъни өйрәнелгән лексик-грамматик материал, тану дәрәҗәсендә генә калмыйча, сөйләмдә мөстәкыйль кулланылу дәрәҗәсенә җиткерелергә тиеш. Дәрес тибы буенча бу дәресләр текст алды дәресләре: **лексик күнекмәләр формалашты-**

**ру** (ЛКФ) **һәм грамматик күнекмәләр формалаштыру** (ГКФ); **текст өстендә эш дәресләре: лексик, грамматик күнекмәләрне камилләштерү дәресләре** (ЛГКК), **диалогик/монологик сөйләм дәресләре** (Д/МС) дип атала. Бу дәресләр циклында өйрәнелгән лексика һәм грамматика турыдан-туры текстта кабатлана, төрле бәйләнешләргә керә, ягъни лингвистик материалны сөйләмдә куллану камилләшә. Тексттан соң булган этапта текст эчтәлеге буенча диалогик-монологик сөйләмгә чыгу дәресләре оештырыла, укучылар материал эчтәлеге буенча спонтан сөйләм – татарча аралашу этабына чыгалар.

Психологлар, методистлар фикеренчә, материалны кат-кат кабатлап, ятлап өйрәнүгә караганда, аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик-грамматик материалны укучыларның мөстәкыйль комбинацияләп сөйләшүе – тел өйрәнүдә күп мәртәбә нәтиҗәлерәк алым. Шуңа күрә дәреслектә эчтәлекне мөстәкыйль сөйләмгә җиткерү өчен, сөйләми (речевые) күнегүләр: диалоглар, ситуатив күнегүләр, иҗади биремнәр еш кулланылды. Дәреслектәге күнегүләрдән тыш, укытучылар түбәндәге методик ярдәмлеккә мөрәҗәгать итә алалар: «Мин татарча сөйләшәм. Я говорю по-татарски». Сборник ситуативных упражнений для русскоязычных учащихся. Авт.: Р. З. Хайдарова, Г. М. Ахметзянова, Л. А. Гиниятуллина. Наб. Челны, 2019.

Телне аралашу ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, укучылар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен шундук тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм тел өйрәнү процессының мотивлашкан булуы тәэмин ителә.

Укучыларның сөйләми активлыгын булдыруда шулай ук уку эшчәнлеген оештыруның **эш режимнарын** дөрес оештыру да бик мөһим. Дәреслектә федераль дәүләт стандартларының таләпләренә туры килгән **парларда, төркемнәрдә, индивидуаль эшләү өчен биремнәр** һәм **иҗади биремнәр** киң урын алды. Алар дәреслектә аерым шартлы билгеләр белән күрсәтелә бардылар.

Укытучы өчен **методик ярдәмлеккә** ишетеп аңлау күнегүләре (аудирование), федераль эш программасы нигезендә төзелгән календарь-тематик план, һәр тема буенча контроль һәм үзконтроль материаллары кертелде.

1) Ишетеп аңлау күнегүләре – һәр дәрестә, дәреснең төрле этапларында кулланылырга тиешле сөйләм эшчәнлеге. Ишетеп аңлау күнегүләренә таләпләр федераль эш программасында киң яктыртылу сәбәпле, методик ярдәмлектә дәрес темалары буенча күнегүләрнең үзләрен бирү белән чикләнелде.

2) Тәкъдим ителгән **тематик план** ел дәвамында өйрәнәсе материалның дәресләргә бүленешен күрсәтә. Һәр дәреснең коммуникатив максаты тематик планда аерым графада күрсәтелә барды, шуңа күрә дәрес планы, дәреснең структур этапларын планлаштырганда, аңа игътибар итү аеруча мөһим.

Федераль эш программасы бүлекләренең эчтәлеге тулысынча дәреслеккә һәм тематик планга салынды, аның үтәлеше күрсәтелә барды. Федераль эш программасы бүлекләренең эзлеклелеге белән дәреслектәге, тематик пландагы эчтәлек бирелеше эзлеклелеге тәңгәл килмәгән очракта да, **дәреслектәге һәм тематик пландагы дәресләр бирелешенең эзлеклелеген алыштырырга тәкъдим ителми**, чөнки федераль эш программасы нигезендә төзелгән дәреслек эчтәлегенең үзара бәйләнеше, системалылыгы бозыла.

3) Укыту процессының уңышлылыгына тәэсир итә торган әһәмиятле факторларның берсе – ул укучыларның белемен **контрольгә** алу. Билгеле булганча, **контроль** укыту барышын көйли, ягъни контрольгә карап, укытучы үз эшчәнлеген оештыра. Методика фәне билгеләгәнчә, укучыларның ятлаганны сөйли белүләре, аерым сүзләрне, җөмләләрне тәрҗемә итә белүләре яисә грамматик категорияләрне аңлый алулары гына **контроль объекты** була алмый. Контрольнең төп объекты булып, укучының өйрәнелгән лексиканы һәм грамматиканы кулланып, **мөстәкыйль аралаша алуы** тора. Календарь-тематик планның коммуникатив максат графасында дәресләр өчен күрсәтелгән **предмет нәтиҗәләре, ягъни тема буенча сөйләшә белү күләме** укучыларның белем дәрәҗәләрен контрольгә һәм үзконтрольгә алуның да эчтәлеге булып тора ала.

## Календарь-тематик план

| № | Дәрес темасы | Дәреснең коммуникатив максаты |
|---|---|---|
| **Белем һәм тормыш (24 сәгать)**<br>**III. Мир вокруг меня** | | |
| 1–3 | Хуш килдең, беренче сентябрь!<br>Сыйфатлар ясалышы | 1 нче сентябрь бәйрәме белән котлый белү; бер-береңә комплиментлар әйтә белү. Яңа уку елына әзерлек турында сөйләшү |
| 4–5 | Минем җәйге ялым. Хикәя фигыльнең заман формаларын кабатлау | Җәйге каникулда кайда булуыңны, ничек ял итү турында сөйләшә белү |
| 6–8 | Хәл фигыль.<br>Хәл фигыльнең 4 төре.<br>Мин иртән мәктәпкә барам | Хәл фигыльне сөйләмдә куллану.<br>Текстны хәл фигыльләр кулланып сөйли белү |
| 9–11 | Мәктәптә беренче көн.<br>Хәл фигыль формаларын сөйләмдә куллану.<br>Без киңәшләр бирәбез | Текстны хәл фигыльләр кулланып сөйли белү.<br>Дустыңа яхшы киңәшләр бирә белү |
| 12–13 | Боерык фигыльнең зат-сан белән төрләнеше.<br>Без бергә дәрес әзерлибез.<br>З. Туфайлованың «Самат» шигыре | Боерык фигыльне диалогик, монологик сөйләмдә куллану. Классташларыңның ничек укуы, нинди билгеләр алуы, өй эшен ничек бергә эшләве турында сөйләшү. Китапны саклап тоту турында киңәшләр бирә белү |
| 14–15 | Рәвеш. Рәвеш төркемчәләре.<br>Без китапханәгә йөрибез | Рәвеш төркемчәләрен сөйләмдә аера белү.<br>Китапханәчедән үзеңә кирәкле китапны сорап ала белү. Нинди китаплар уку турында сорый, әйтә белү |
| 16 | Исемнәргә кушымчалар ялгану тәртибе | Исемнәргә кушымчаларны дөрес ялгау. Уку-язу әсбапларының нинди булуын, кемнеке икәнен әйтә белү |
| 17–18 | Р. Вәлиевнең биографиясе һәм иҗаты | Р. Вәлиев турында мәгълүматны кыскача сөйли белү |
| 19–20 | Р.Вәлиевнең «Икеле» шигыре.<br>*Үзем* билгеләү алмашлыгының килеш белән төрләнеше | Шигырьне сәнгатьле уку.<br>Эшне үзең башкаруың турында әйтә белү.<br>Уңышсызлыкларыңда башкаларны гаепләүнең начар сыйфат булуы турында сөйләшү |
| 21–24 | Ш. Маннурның «Киңәш» шигыре.<br>Яхшы уку кагыйдәләре.<br>*«Инфинитив + кирәк»* төзелмәсе | «Яхшы уку кагыйдәләре», «Уку хезмәте», «Белем байлыктан кыйбат» темалары буенча сөйләшү |

| | | |
|---|---|---|
| **Мин һәм минем яшьтәшләрем (13 сәгать)**<br>**I. Мир моего «Я»** | | |
| 25–27 | Безнең дусларыбыз. Алар нинди?<br>Ясалма сыйфатлар<br>(*-лы/-ле, -сыз/-сез* кушымчалары) | Кешенең тышкы кыяфәтен, характерын билгеләүче сыйфатларны әйтә белү.<br>Дустың турында сөйли белү |
| 28–30 | Әдәп кагыйдәләре.<br>Гарәп-фарсы алынмалары | Әдәп кагыйдәләрен сөйли белү, аларның кирәклеге турында әңгәмә кору |
| 31–32 | З. Әхмәровның «Әләкче» хикәясе.<br>Хикәяне сәхнәләштерү | Хикәяне сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйли белү.<br>Әләкләшүнең начар сыйфат булуын текст эчтәлегенә таянып дәлилли белү; геройга киңәшләр бирә белү |
| 33–34 | Сашаның дуслары.<br>Без хикәя язабыз | Хикәяне сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйли белү.<br>Хикәя эчтәлегенә нигезләнгән диалоглар буенча сөйләшә белү.<br>Дуслар арасында бер-береңә ярдәмләшүнең кирәклеге турында фикер алышу |
| 35–37 | Без яшьтәшләребез белән ничек аралашабыз?<br>Исем фигыль. Исем фигыльнең барлык һәм юклык формасы | Әңгәмәдәшең белән аралашу кагыйдәләре турында сөйләшү |
| **Буш вакыт (17 сәгать)**<br>**I. Мир моего «Я»** | | |
| 38–40 | Буш вакыт – ул нинди вакыт?<br>Җөмлә кисәкләре.<br>Минем буш вакытым булса, ... | Буш вакытны ничек үткәрү турында сөйләшү.<br>Яраткан шөгылең турында сөйли белү.<br>Татарстандагы сәяхәт урыннары турында сөйли белү |
| 41–43 | Теркәгечләр. Тезүче һәм иярүче теркәгечләр.<br>Гади һәм кушма җөмләләр.<br>Минем буш вакытым | Теркәгечләрне сөйләмдә куллана белү. Буш вакытны ничек үткәрү турында сөйләшү |
| 44–46 | Исем фигыльнең барлык формасы.<br>Кереш сүзләр.<br>Файдалы, файдасыз үткәрелгән буш вакыт | Концертка, театрга бару турында сөйләшү.<br>Караган тамашага бәя бирү. Яшьтәшләрнең үз-үзләрен җәмгыять урыннарында тотышы турында сөйләшү, бәя бирә белү |
| 47–50 | Ш. Галиевнең «Ялгыш адым» шигыре.<br>Нәрсә ул егетлек?<br>Бездәге үрнәк сыйфатлар | Шигырьне сәнгатьле уку.<br>«Нәрсә ул егетлек?» проблемасы буенча сөйләшү. Буш вакытны ничек үткәрү турында сөйләшү |
| 51–54 | Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше.<br>Р. Миңнуллинның «Подъезддагы язулар» шигыре.<br>Безнең йортның подъезды | Шигырьне сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйли белү. «Безнең йортның подъезды» дигән тема буенча сөйләшү.<br>Җыену көне турында сөйләшү |

| | | |
|---|---|---|
| **Өлкәннәр һәм кечкенәләр (17 сәгать)**<br>**I. Мир моего «Я»** | | |
| 55–57 | Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре. Җөмләнең иярчен кисәге – аергыч.<br>Өлкәннәр һәм кечкенәләр мөнәсәбәте | Гаиләдәге мөнәсәбәтләр, өлкәннәрне хөрмәт итү турында сөйләшү |
| 58–59 | Җөмләнең иярчен кисәге – тәмамлык.<br>Тәрбиялелек сыйфатлары | Тормышта аралашуда әдәплелек кагыйдәләре турында сөйләшү |
| 60–61 | Җөмләнең иярчен кисәге – хәл. Бер-беребезгә булышабыз. «Ярдәмләшеп яшәү күңелле» темасы буенча хикәя язу | Яшьтәшләрең белән ярдәмләшеп яшәү турында сөйләшү |
| 62–64 | Исем фигыльләрнең сөйләмдә кулланылышы.<br>Р. Мингалимнең «Иң зур кеше» шигыре.<br>Кисәкчәләр. Кисәкчәләрнең дөрес язылышы | Өлкәннәрне хөрмәт итү кирәклеге турында сөйләшү. Кисәкчәләрне сөйләмдә куллана белү |
| 65–67 | Тәрбияле булу заманчамы? Гаиләдә тәрбиялелек кагыйдәләре. | «Тәрбияле булу заманчамы?» «Гаиләдә тәрбиялелек» темалары буенча сөйләшү |
| 68–71 | Аралашу әдәбе.<br>Ш. Галиевнең «Тагын бер рәхмәт» шигыре.<br>Билгеләү алмашлыклары.<br>М. Газизовның «Рәхмәт» шигыре | Шигырьләрне сәнгатьле уку, эчтәлектә бирелгән проблемалар буенча сөйләшә белү. Тәрбияле аралашу әдәбе турында сөйләшү |
| **Туган ягым табигате (14 сәгать)**<br>**IV. Моя Родина** | | |
| 72–73 | Туган ягым – Татарстан.<br>И. Юзеевның «Татарстаным» шигыре | Шигырьне сәнгатьле уку. Татарстан табигате турында сөйләшү |
| 74–75 | Г. Бәшировның «Безнең Татарстан» хикәясе.<br>Татарстанның табигате | Татарстанның табигате, аның байлыгы, анда яшәүче хайваннар, кошлар турында сөйли белү |
| 76–78 | Татарстан елгалары | Нинди елгалар барлыгы, алар турында тексттан мәгълүматларны табып, диалогларда куллана белү |

| | | |
|---|---|---|
| 79–80 | Л. Леронның «И ямьле дә соң дөнья!» хикәясе.<br>Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре.<br>Тамыр һәм ясалма исемнәр | Һәр ел фасылының матурлыгы турында сөйли белү.<br>Әйтү максаты ягыннан төрле җөмләләр кулланып, үзең яраткан ел фасылы турында хикәя язу |
| 81–82 | Р. Корбанның «Җиләктә» шигыре.<br>Вакыт формаларын кабатлау.<br>Күрсәтү алмашлыклары | Урманга барганың, җиләк җыйганың турында сөйли белү; вакытны кулланып, кайчан барганыңны (кайтканыңны) әйтү.<br>Күрсәтү алмашлыкларын таба, тәрҗемә итә белү |
| 83–85 | Татарстанның географик урыны, климаты, байлыклары.<br>Без Татарстанда яшибез | Татарстанның территориясе, аның географик урыны, чикләре, табигый байлыклары турында сөйли белү |
| **Башкалабыз Казан (17 сәгать)<br>IV. Моя Родина** | | |
| 86–88 | Башкалабыз Казан | Казанның истәлекле урыннарын әйтә белү.<br>Күрсәтү алмашлыкларын кулланып, Казан шәһәренең истәлекле урыннары турында диалоглар төзү |
| 89–90 | Татарстан Республикасының Милли китапханәсе.<br>Без китапханәдә | Беренче китаплар, Милли китапханә турында мәгълүматлар табып сөйли белү.<br>Китапханәгә бару, нинди китаплар алу турында сөйләшә белү |
| 91–93 | Казан – театрлар шәһәре.<br>Ялгызлык исемнәр | Казандагы театр исемнәрен әйтә белү.<br>Кайсы театрга бару, нинди тамашалар карау, билетлар алу турында сөйләшә белү.<br>Татарстанда һәм үзең яшәгән төбәктәге композиторлар, язучылар, шагыйрьләр, рәссамнар, җырчыларның исемнәрен әйтә белү |
| 94–95 | Бакый Урманче – Татарстанның халык рәссамы | Рәссам, сынчы Бакый Урманче иҗаты турында кыскача сөйли белү |
| 96–98 | Сара Садыйкова иҗаты.<br>«Үз илемдә» җыры | Җырчы, композитор Сара Садыйкова иҗаты турында кыскача сөйли белү |
| 99–102 | Без туган илебез белән горурланабыз.<br>Максат белдерү формалары | Текстны сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйли белү.<br>Туган илебез белән горурлану хисләрен әйтә белү.<br>*Өчен* бәйлеген исем фигыль, билгесез киләчәк заман хикәя фигыль формалары белән кулланып, максат белдерү |

## Ишетеп аңлау күнегүләре

## Белем һәм тормыш

### 1–3 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [җ].**
бүген, җәй, кояшлы, җылы, яңгырлы, була, җиләк, аеруча, искиткеч

**2. Укажите слова, отвечающие на вопрос *кайчан?***
бүген, күңелле, салкын, яңгырлы, иртәгә, кояшлы, кичен, җилле

**3. Прослушайте и поставьте нужные реплики.**
– ... ?
– Белем бәйрәме.
– Син бәйрәмгә ничек әзерләнәсең?
– ... .

### 4–5 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ы̆].**
авылда, булыштым, каникулда, Төркиядә, лагерьда, очтым, юындым, ашадым

**2. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *кайда?***
авылда, шәһәрдә, булыштым, каникулда, Төркиядә, лагерьда, укучы, алды

**3. Прослушайте и скажите, как изменятся глаголы, если бы эти действия не происходили.**
булыштым, очтым, юындым, су коендым, кызындым, ял иттем

**4. Прослушайте и переведите на татарский язык.**
1) В этой сумке есть учебники и тетради.
2) Они все новые, чистые.
3) Я готов к новому учебному году.

**5. Прослушайте и закончите текст.**

Бүген икенче сентябрь. Көн кояшлы, матур. Мин яңа киемнәр кидем … .

## 6–8 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ə̆].**

безнең, укучы, сыйныфта, гына, тырышып, имтихан, көндәлек, билгеләр, күңелле

**2. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**

дәрес әзерлим, китап укыйм, имтихан тапшырам, мәсьәлә чишәм, кер юам, рәсем ясыйм, шигырь ятлыйм, хикәя язам

**3. Прослушайте и укажите деепричастия.**

шатланган, килә, кайткан, язгач, бүген, көлә-көлә, әзерләп, язып, сөйли-сөйли, кайтканчы

**4. Прослушайте и дополните предложения.**

1) Безне күргәч, ... .
2) Дәрес әзерләгәнче ... .
3) Диктант язып ... .
4) Алсу, китап укый-укый, ... .

**5. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении.**

1) Безне күргәч, кояш көлә,
   Шатланганны ул да белә.
2) Безне күргәч, кояш көлә,
   Сөенгәнне ул да белә.

**6. Прослушайте и подберите антонимы к данным словам.**

көлә – ...
арттан – ...
белә – ...
алдык – ...
килә –...
килә – …

## 9–11 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ы̆].**

уяндым, тордым, кидем, бирәчәк, керәчәк, юындым, ашадым, алдым, килдем

**2. Прослушайте и скажите, как изменятся глаголы, если бы эти действия не происходили.**

көттем, уяндым, тордым, ясадым, юындым, ашадым, кидем, алдым, бирәчәкләр, керәчәк

**3. Прослушайте и переведите на татарский язык.**

1) В этом году у нас будет новый директор.
2) Я люблю этот день.
3) Нас встретил классный руководитель.
4) По дороге я встретил своих друзей.

**4. Прослушайте и закончите текст.**

Бүген икенче сентябрь. Көн кояшлы, матур. Мин мәктәпкә киттем. ...

**5. Прослушайте и укажите предложения, в которых действия уже произошли.**

1) Мин бүген иртә уяндым.
2) Зарядка ясадым, юындым, киендем.
3) Сумкамны алам да мәктәпкә китәм.
4) Безнең бүген яңа дәресләр булачак.

## 12–13 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**

һәркем, барсын, күрсен, күрмәсен, бирә, шәһәр, берничә, җиденче

**2. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопросы *ничә? ничәнче?***

бишенче класста, алты хата, ундүрт сорау, унике ел, алтынчы дәрес

**3. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них подходящие местоимения *син, ул*.**

ал, бирсен, күрсен, кил, әйт, ашасын, чакыр, сөйләсен, укысын, пычратма

**4. Прослушайте и укажите слова с твёрдым произношением.**

кызык, кызып-кызып, алып кайткач, укып яткач, китергән, беркем

**5. Прослушайте и укажите лишнее слово в грамматическом ряду.**

селтәп атты, менеп ятты, китап, телгә килде

**6. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нишләсен?***

селтәп атсын, менеп ятсын, җырлый, бирә, килә, бирмәсен, кермәсен

### 14–16 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и скажите слова со звуком [ә].**

тиз, дусларча, эшләде, шактый, иртәгә, ерак, якын, югары, түбән

**2. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении.**

1) Мин китапны укып бетердем. Мин китапны тиз укып бетердем.
2) Айнур текстны акрын укыды. Айнур текстны акрын укыды.
3) Мин мисалны эшләдем. Мин мисалны ялгыш эшләдем.
4) Рус теленнән контроль диктант яздык. Бүген рус теленнән контроль диктант яздык.

**3. Прослушайте предложения и в слове китапханә вставьте нужные аффиксы.**

1) Мин китапханә... килдем.
2) Мин китапханә... китап укыйм.
3) Мин китапханә... китап алдым.

**4. Прослушайте и укажите предложения, в которых есть слова, отвечающие на вопрос *нинди?***

1) Мәктәп китапханәсе зур, матур.
2) Без китапханәгә еш йөрибез.

3) Китапханәче апа тиз генә китаплар сайларга булыша.
4) Мин бу айда ике кызыклы китап укыдым.

**5. Прослушайте и закончите предложения.**
1) Мин кибеттән китап ... .
2) Син китапларыңны чиста, пөхтә ... .
3) Ул авырый, шуңа күрә ... .
4) Наил дәрескә ... .
5) Син ашыгып язганга күрә, сүзләрдә ... .

## 17–20 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ə̆].**
гаепле, эш, үзем, чишә, булыша, сорый, икеле, мәсьәлә, әзерли

**2. Прослушайте и определите падежи.**
үземне, үземдә, үзем, үземә, үземнең, үземнән

**3. Прослушайте и скажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**
1) Рамазан икеле алган. Рамазан математикадан икеле алган.
2) Рамазан үзе чишкән. Рамазан мәсьәләне үзе чишкән.
3) Мин нишли алам? Мин берүзем нишли алам?
4) Әби икеле алды. Күпме тырышса да, әби икеле алды.

**4. Прослушайте и найдите правильное утверждение.**
1) Рамазан икеле алган. Әби икеле алган.
2) Рамазан үзе гаепле. Рамазанның әти-әнисе гаепле.
3) Рамазанга әбисе булышкан. Рамазанга беркем дә булышмаган.

## 21–24 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**
уй, кат-кат, күңел, дөрес, җитез, үлчә, көлә, кис

**2. Прослушайте и укажите двусложные слова.**
дөрес, язу, уй, кис, җитез, якты, югары, бәя

**3. Прослушайте и определите глаголы повелительного наклонения.**
кара, уйла, уйлап, язып, үлчә, ачып, кис

**4. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя местоимение *минем, синең, аның.***
күз, күңел, уй, китап, баш

**5. Прослушайте и закончите предложения.**
1) Син ялгыш … .
2) Син кат-кат … .
3) Синең китабың ... .
4) Синең дәфтәрең ... .

**6. Прослушайте и найдите правильное утверждение.**
1) Эшмәкәр булу өчен белем кирәк. Эшмәкәр булу өчен кыюлык та җитә.
2) Бер галим бер наданны җиңә. Бер галим йөз наданны җиңә.

**Мин һәм минем яшьтәшләрем**

**25–30 нчы дәресләр**

**1. Прослушайте и укажите слова со звуками [ы].**
тырыш, тәрбияле, горур, акыллы, куркак, алдакчы, надан, акылсыз, әдәпле

**2. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**
тәрбияле, әдәпле, акыллы, күңелле, кирәкле, игътибарлы, әдәпсез, тәмле телле

**3. Прослушайте и назовите те качества, которые указывают на характер человека.**
ябык, тупас, озын, кыска, аралашучан, кечкенә, тәрбиясез, матур, киң күңелле, озын чәчле, тыйнак

**4. Прослушайте и закончите предложения.**
1) Әгәр кеше белемле булса, ... .
2) Әгәр кеше надан булса, ... .

3) Әгәр кеше әдәпле булса, ... .
4) Әгәр кеше усал булса, ... .

**5. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Әдәп кагыйдәләрен кайберәүләр кирәксез дип саный. Әдәп кагыйдәләрен кемнәрдер кирәксез дип саный.

2) Кайберәүләр гаепне башкалардан эзләргә ярата. Кайберәүләр һәрвакыт гаепне башкалардан эзләргә ярата.

3) Әдәп кагыйдәләрен барлык кешеләр дә үти. Әдәп кагыйдәләрен барлык кешеләр дә үтәргә тиеш.

## 31–34 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуками [w].**
ваза, ватык, Фатих, авыр, вагон, тау, авыл, алдау, авыз

**2. Прослушайте и измените слова по образцу.**
О б р а з е ц : *эшли – эшләргә ярата*
әләкләшә, алдаша, көлә, укый, сөйли, өйрәтә

**3. Прослушайте и найдите правильное утверждение.**
1) Мидхәт әләкләшергә ярата. Мидхәт әләкләшергә яратмый.
2) Фатих тәрәзәне ваткан. Фатих тәрәзәне ватмаган.
3) Әләкче кешене яраталар. Әләкче кешене яратмыйлар.
4) Чын дус Мидхәт кебек була. Чын дус Азат кебек була.
5) Сашаның дуслары күп. Мидхәтнең дуслары күп.

**4. Прослушайте и скажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Алар бергә дәрес әзерлиләр. Алар бергә уйныйлар, дәрес әзерлиләр.
2) Ул дусларын күрде. Ул дусларын күрде һәм ярдәм сорады.
3) Азат акча җыйган иде. Азат яңа уен алырга акча җыйган иде.
4) Улым, дару алып кайт әле. Улым, даруханәдән йөрәк даруы алып кайт әле.

## 35–37 нче дәресләр

**1. Прослушайте и измените по образцу.**

Образец: *ярата – ярату*

укый, эшли, кайгырта, сөйли, бара, көлә, уйный, ашый, аралаша, сорый

**2. Прослушайте и поставьте имена действия в отрицательную форму.**

Уку, күрү, туктау, төзәтү, сөйләшү, аралашу, уйлау, табу, белү.

**3. Прослушайте и закончите предложения.**

1) Аралашучан кеше булу өчен, ... .
2) Әгәр син ялгыз калырга теләмәсәң, ... .
3) Яхшы дусларың булсын дисәң, ... .

## 38–40 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуками [ы], [у].**

вакыт, туктаусыз, кызыклы, буш, файдалану, кайберәүләр, файдасыз

**2. Прослушайте и укажите лишнее словосочетание в логическом ряду.**

буш вакыт, ял вакыты, эш вакыты, күңел ачу, ирекле вакыт

**3. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому подходящее прилагательное.**

вакыт, ял, эш, фильм, китап, тапшыру

**4. Прослушайте и закончите предложения.**

1) Без, укучылар, буш вакытны ... .
2) Бүген, ягъни дәрестән соң, ... .
3) Минем сыйныфташ Оля ял вакытын ... .

## 41–43 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите союзы.**

вакыт, ләкин, урамда, әмма, ятам, әгәр, төрле, ирекле, тик, файда, һәм, үзем, әле, чөнки, ә.

**2. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них подходящие местоимения *минем, синең, аның.***

вакытың, ялым, тапшырулары, китабың, йөрәге, дусларым

**3. Прослушайте и назовите глаголы во 2 лице единственного числа.**

файдаланасың, аңламый, яши, йөрибез, булышасыз, үткәрә, онытмыйсың

**4. Прослушайте и скажите, что пропущено во втором предложении каждой пары.**

1) Буш вакытны яхшы файдаланырга кирәк. Буш вакытны файдаланырга кирәк.

2) Мин үзем теләгәнчә яшим. Мин яшим.

3) Буш вакытта ул китаплар укырга ярата. Буш вакытта ул укырга ярата.

4) Буш вакытым булса, мин әти белән шахмат уйныйм. Буш вакытым булса, мин шахмат уйныйм.

5) Урам буйлап файдасызга йөрүне мин аңламыйм. Урам буйлап йөрүне мин аңламыйм.

**5. Прослушайте и закончите предложения.**

1) Буш вакыт – ул ... .

2) Буш вакытта мин ... .

3) Буш вакытны файдалы ... .

4) Буш вакыт булса, ... .

## 44–46 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите имена действия.**

утыралар, тәмәке тарту, файдалы үткәрү, ял итәләр, сәламәтлек саклау, авырый, музыка тыңлау

**2. Прослушайте и добавьте к каждому существительному соответствующее прилагательное.**

апа, яшьләр, малайлар, вакыт, гадәт, яхшылык

**3. Прослушайте и закончите предложения.**

1) Мин риза, ... .

2) Мин синең белән килешәм, ... .

3) Минемчә, бу дөрес түгел, чөнки ... .

## 47–50 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ы̆].**

асылынып бара, егетлек, шаярып йөри, ябышып бара, чаялык, өлгерлек, ялгыш, култык таягы

**2. Прослушайте и выберите глаголы с окончаниями прошедшего определённого времени.**

ял итте, арып бетә, биеде, ялгыш баса, бара, күрсәтте, уйный, күңел ача

**3. Прослушайте и подберите к данным словам антонимы.**

куркак, куркаклык, тәрбияле, тәртипсез, ялгыш

**4. Прослушайте и закончите предложения.**

1) Трамвайга асылынып бару – ... .
2) Трамвайга асылынып бару – көчлелек ... .
3) Трамвайга асылынып бару – бушка ... .
4) Әнигә ярдәм итү – ... .
5) Әтигә ярдәм итү – ... .

**5. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Мин кичә ял иттем.
   Мин кичә бик яхшы ял иттем.

2) Без кичә циркка бардык.
   Без кичә гаилә белән циркка бардык.

3) Бик күңелле булды, ял иттек.
   Бик күңелле булды, рәхәтләнеп ял иттек.

## 51–54 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [а°].**

язылмаган, язылган, сызылмаган, сызылган, бутый, мактау, хәтта, дошман

**2. Прослушайте и укажите количество слогов в словах.**

йортка, подъезддан, тактаны, подъездыннан, мактамас, дошман, дус, мактар

**3. Прослушайте и скажите, как изменились бы аффиксы этих глаголов, если бы действия не происходили.**

язылган, сызылган, яза, мактый, булды, боргалый, калдыра, дәвам итә

**4. Прослушайте и переведите.**

1) Стенага язганнар.
2) Тактага язарга кирәк.
3) Начар сүзләр язганнар.
4) Тактага көнегүне язарга кирәк.
5) Бабайлар рейхстагка язганнар.
6) Малайлар тактага язсыннар.

**5. Прослушайте и, если не согласны, дайте отрицательный ответ.**

1) Малайлар класс тактасына язсыннар.
2) Алар стенага матур сүзләр язсыннар.
3) Бабайлар сугышта катнашканнар.
4) Бу малайлар – тәртипле балалар.
5) «Аңгыра» сүзе – яхшы сүз.
6) Бабайлар кебек кыю булырга кирәк.

## Өлкәннәр һәм кечкенәләр

### 55–57 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ө].**

өлкәннәр, оныклар, мөнәсәбәт, кечкенәләр, очрашу, хөрмәт итә, рәхәт, төрле

**2. Прослушайте и укажите глаголы в отрицательной форме.**

уйный, тыңламый, хөрмәт итә, сорау бирә, булышмый, аралаша, ялгыша, эшләми, яза

**3. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому подходящие местоимения *мин, син, ул, алар.***

сорау бирәм, ялгыша, эшлисең, пешерәләр, хөрмәт итәм, аралашасың, яшиләр

**4. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Кечкенәләр – өлкәннәрнең оныклары. Кечкенәләр – өлкәннәрнең кызлары, уллары.

2) Кечкенәләр яшәргә тели. Кечкенәләр үзләренчә яшәргә тели.

3) Кечкенә чакта ялгышлар була. Кечкенә чакта төрле ялгышлар була.

**5. Прослушайте и закончите текст.**

Өлкәннәр дип без әби-бабайларга, апа-абыйларга әйтәбез. Ә кечкенәләр – аларның кызлары һәм уллары. ...

## 58–59 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова с мягкими гласными.**

басма, куллар, өлкән, хөрмәт, юл, мәктәп, бөтен, тәртипсез

**2. Прослушайте и образуйте слова во множественном числе.**

кул, өлкән, басма, юл, урман, вакыт, хата

**3. Прослушайте и измените слова по образцу.**

О б р а з е ц : *хата ясый – хата ясамый*

юл бирә, хөрмәт итә, мәктәпкә бара

**4. Прослушайте и укажите предложения, в которых есть слова, отвечающие на вопрос *кайда?***

1) Тар басмада Илдар белән Ирек очраштылар.

2) Мәхмүт мәктәпкә чапты.

3) Урамда ул бер ападан: «Вакыт күпме?» – дип сорады.

## 60–61 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**

яшьтәшләр, очрашырга, һәрвакыт, үзләренчә, балалар, тиеш, өлкәннәрне, хөрмәт, еш, яратабыз

**2. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нинди?***

файда, акыллы, намуслы, чиста, акыл, хөрмәт, тормыш, хөрмәтле, яшьтәшләр

**3. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них местоимения *мин, син, ул.***

омтылам, кайгырта, эшлисең, яшим, беләсең, сөйли, китерә, уйныйм, тыңлый, хөрмәт итәм, сорау бирәсең, булыша, аралашам

**4. Прослушайте и скажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Кеше яхшылыкка омтыла. Яхшылыкка омтылу – яхшы гадәт.

2) Өлкәннәргә һәрвакыт булышу кирәк. Өлкәннәргә һәрвакыт булышасы килә.

3) Өлкәннәр белән әдәпле аралашу кирәк. Өлкәннәр белән әдәпле аралашырга телим.

4) Яшьтәшләр белән очрашу күңелле булды. Яшьтәшләр белән очрашырга телим.

## 62–64 нче дәресләр

**1. Прослушайте и измените слова по образцу.**

Образец: *зур – зуррак, бик зур, иң зур*

кечкенә, авыр, олы

**2. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них существительное по смыслу.**

күп ... , зур ... , ак ... , йомшак ... , кызыл ...

**3. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Күпне белгән **–** зур кеше.
Күпне белгән кешене зур кеше дияргә мөмкин.

2) Әти-әни **–** иң зур кеше.
Әти-әнине хөрмәтләүче кеше дә – иң зур кеше.

**4. Прослушайте и переведите на татарский язык.**
1) Надо уважать друзей.
2) Надо уважать своих родителей.
3) Надо уважать взрослых.

**5. Прослушайте и измените глаголы по образцу.**
Образец: *хөрмәт итә* **–** *хөрмәт итми*
ярата **–** …
хәлен белә **–** …
оныта **–** …
тыңлый **–** …

**65–67 нче дәресләр**

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**
чират, гаилә, аралашу, әдәплелек, тәрбия, якыннар, ихтирам, караш, әни, әгәр

**2. Прослушайте и скажите, как изменились бы аффиксы этих глаголов, если бы действия не происходили.**
беләм, ябасың, бирәм, чыгасың, көләләр, көтәсең, эндәшәләр, тәрбияли

**3. Прослушайте и закончите предложения, попросив вежливо.**
1) Ишекне яп ... .
2) Дәфтәреңне бир ... .
3) Бүлмәдән чык ... .

**4. Прослушайте и подберите антонимы к данным словам.**
яп **–** …
чык **–** …
бир **–** …
тәрбияле **–** …
көлә **–** …

**5. Прослушайте и закончите предложения.**
1) Без гаиләдә ... .
2) Һәр бала ... .
3) Аралашу әдәбен гаиләдә ... .

## 68–71 нче дәресләр

**1. Прослушайте и выделите слова, которые указывают на действие прошедшего неочевидного времени.**

чыгардым, биргән, эшләр, сорады, куйган, тырыша, керә, әйткән, сөйләгән

**2. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**

әби, бабай, малай, абзый, тырыша, әни, әти

**3. Прослушайте и измените числительные на порядковые.**

ике, өч, бер, җиде

**4. Прослушайте и закончите предложения.**

1) Малай трамвайда урын ... .
2) Малай әбигә урам аркылы чыгарга ... .
3) Малай күрше хәлен ... .
4) Сәлим үзе эшләгән яхшылыкларны ... .

## Туган ягым табигате

## 72–78 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**

Татарстан, татар, ике, дәүләт, тел, минем, зәңгәр, Агыйдел, төрле, эссе, һәркем

**2. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении.**

1) Минем туган ягым – Татарстан. Минем туган җирем – Татарстан.
2) Татарстан аркылы зур елгалар ага. Татарстан буйлап зур елгалар ага.
3) Татарстанны елгалар иле дип йөртәләр. Татарстанны дүрт елга иле дип йөртәләр.
4) Татарстанның климаты уртача. Татарстанның һавасы уртача.

**3. Прослушайте и закончите предложения.**

1) Татарстанның мул сулары, ... .
2) Татарстанның табигате ... .

3) Җил дә вакытында исә, ... .
4) Татарстанда калын урманнар да, ... .
5) Чулман – ... .

**4. Прослушайте слова, подберите к ним антонимы.**
күп, эссе, биек, киң, тәмле, зур, салкын.

**5. Прослушайте числительные и запишите их словами.**
500, 180, 40, 380, 598, 445

**6. Прослушайте и выберите правильное утверждение.**
1) Татарстан аркылы Идел, Енисей, Кама, Вятка, Агыйдел, Ык елгалары ага. Татарстан аркылы Идел, Вятка, Чулман, Агыйдел, Ык елгалары ага.
2) Каманың борынгы исеме – Чулман. Каманың борынгы исеме – Нократ.
3) Идел Камадан зуррак. Чулман Иделдән зуррак.

**79–82 нче дәресләр**

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ы].**
ел фасылы, яңгыр, ябалак, сусыл, исәпсез-хисапсыз, шифалы яңгырлар, алтынсу, умырзая, пыяла, карлы

**2. Прослушайте и подберите по образцу к прилагательным подходящие по смыслу имена существительные.**
О б р а з е ц : *киң – киң кырлар*
ап-ак, карлы, ләйсән, яшел, сусыл, җылы, шифалы, алтынсу, күңелле

**3. Прослушайте и определите правильные варианты утверждений.**
1) Язын агачларның яфраклары коела.
2) Җәй көне урманда җиләк күп була.
3) Көзен төннәр кыскара, көннәр озыная.
4) Кышын ябалак-ябалак кар ява.

**4. Прослушайте и составьте диалог, используя вопросы.**
1) Татарстанның табигате нинди?
2) Татарстанда нинди зур елгалар бар?
3) Татарстанның климаты нинди?
4) Нинди ел фасыллары бар? Кайсы ошый? Ни өчен?

## 83–85 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ө].**

чикләшә, өлкә, мәйдан, төньяк, көньяк, климат, көнчыгыш, көнбатыш, салкын

**2. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нәрсә?***

яшиләр, мәйдан, күмер, пыяла, ком, чыгаралар, бакыр рудасы, ташкүмер

**3. Прослушайте и переведите.**

север, запад, восток, земля, государство, площадь

**4. Прослушайте и скажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Татарстан Республикасы Идел белән Каманың кушылган җирендә урнашкан. Татарстан Республикасы Европаның көнчыгышында, Идел белән Каманың кушылган җирендә урнашкан.

2) Татарстан төрле өлкәләр белән чиктәш. Татарстан Башкортстан, Чувашия, Марий Эл, Ульяновск, Киров, Оренбург өлкәләре белән чиктәш.

## Башкалабыз Казан

## 86–93 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ҡ].**

Казан, кеше, бөек, Тукай, карточка, халык, күп, урнашкан, корылма, күпер, үзәк

**2. Прослушайте и скажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Казан данлыклы шәһәр санала. Казан дөньякүләм данлыклы шәһәр санала.

2) Бауман урамы кешеләр өчен ял итү үзәге булып тора. Бауман урамы кешеләр өчен ял итү һәм сәүдә үзәге булып тора.

3) Миңа китап кирәк. Миңа Муса Җәлил турында китап кирәк.

4) Беренче китаплар борынгы Мисырда барлыкка килгән. Беренче китаплар 5 мең еллар элек борынгы Мисырда барлыкка килгән.

**3. Прослушайте и закончите предложения.**
1) Николай Второв бу китапханәгә ... .
2) Беренче китаплар ... .
3) Беренче татар басма китабы ... .

**4. Прослушайте и составьте по образцу составные имена прилагательные. Составьте предложения.**
О б р а з е ц : *Муса Җәлил – Муса Җәлил исемендәге*
Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин, Василий Качалов, Габдулла Кариев

**5. Прослушайте начало диалога, дополните.**
– Саша, әйдә театрга барабыз.
– Ә билетлар бармы?
– ... .

## 94–98 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [һ].**
халык, архитектор, һәм, шәхес, художник, һәйкәл, шәһәр, мәхәббәт

**2. Прослушайте и скажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Бакый Урманче – Татарстанның халык рәссамы, график һәм архитектор. Бакый Урманче – Татарстанның халык рәссамы, сынчы, график һәм архитектор.

2) Сара Садыйкова ике комедиягә музыка, романслар, вальслар иҗат иткән. Сара Садыйкова өч йөздән артык җыр, ике комедиягә музыка, романслар, вальслар иҗат иткән.

3) Кырлайда Бакый Урманче хезмәтләре бик күп. Кырлайда Габдулла Тукай әдәби-мемориаль комплексында Бакый Урманче хезмәтләре бик күп.

4) Аның җырларын профессиональ артистлар бик яратып җырлый. Аның җырларын профессиональ артистлар да, халык та бик яратып җырлый.

**3. Прослушайте и закончите предложения.**
1) Бакый Урманче үзенең иҗатында ... .
2) Музейда рәссамның ... .
3) Яр Чаллы шәһәренең концертлар залы ... .
4) Аның җырларын ... .

## 99–102 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**

җир, туган, өлкә, кеше, уллары, туфрак, милләт, дәүләт, мул, намуслы

**2. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нинди?***

файда, акыллы, шартлар, намуслы, мул сулы, кайнар йөрәкле, тормыш, әкият

**3. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них местоимения *мин, син, ул.***

барасы килә, эшли, яши, белә, сөйли, китерә

**4. Прослушайте и скажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Кеше яхшылыкка омтыла. Кеше гомере буе яхшылыкка омтыла.

2) Туган илебезне әкият иле итәсе килә. Туган илебезне, ягъни Татарстаныбызны әкият иле итәсе килә.

3) Яшь буын үсеп килә. Яшь буын, минем яшьтәшләрем үсеп килә.

**5. Прослушайте и закончите предложения.**

1) Безнең Татарстан ... .

2) Туган илебезне ... .

3) Татарстан халыклары ... .

4) Татарстанның киләчәге ... .

## Контроль һәм үзконтроль өчен үрнәк биремнәр

### Белем һәм тормыш

**1. Переведи.**

Новые учебники, старательно учиться, слушать, выполнять домашнее задание, хорошая оценка, решил примеры, решил задачу, надо внимательно слушать, не забывай.

**2. Как скажешь о том, что:**

– в вашей школе начал работать новый директор;
– вам раздали новые учебники;
– вы будете учиться в первую смену;
– в ваш класс пришли два новых ученика?

**3. Дополни диалог.**

– ... ?
– Мин җәйге каникулда диңгездә булдым. Ә син?
– ... .

**4. Дополни диалоги.**

1) – ... ?
– Әйе, мин татар теленнән өй эше эшләдем.
– Нинди өй эше эшләдең?
– ... .

2) – ... ?
– Мин дүртле (бишле) алдым.

**5. Спроси у друга:**

– какие оценки он получил сегодня;
– правильно ли он решил задачу;
– правильно ли он решил примеры.

**6. Продолжи диалоги.**

1) – Сез татар теле дәресендә нишлисез?
– ... .

2) – ... ?
– Без математика дәресендә мәсьәләләр, мисаллар чишәбез.

**7. Предложи младшей сестре:**
– вместе делать домашнее задание;
– вместе решить задачу.

**8. Посоветуйте сестрёнке:**
– старательно учиться;
– не разговаривать на уроке;
– слушать учителя;
– выполнять домашнее задание.

**9. Дополни диалог.**
– ... ?
– Әйе, китап укырга яратам.
– Нәрсә турында укыйсың?
– ... .

## Мин һәм минем яшьтәшләрем

**1. Напишите о своём друге по плану:**
1) Внешность моего друга.
2) Характерные черты моего друга.
3) Его увлечения.
4) Совместные занятия.

**2. Переведи.**
Свободное время, нравится, любимое занятие (увлечение), полезный, после уроков, спортивный кружок, занимаюсь спортом, отдыхаю.

**3. Дополни диалоги.**
1) – Петя, вакытың ничек үтте?
– ... .
– Ни өчен файдалы үтте?
– Чөнки ... .

2) – ... ?
   – Буш вакытта китаплар укыйм.
   – Нинди китаплар укырга яратасың?
   – ... .

**4. Как скажешь о том, что в свободное время любишь:**
– слушать музыку;
– читать книги;
– гулять с друзьями;
– смотреть телевизор;
– кататься на велосипеде?

**5. Спроси у друга, любит ли он в свободное время:**
– слушать музыку;
– читать книги;
– гулять с друзьями;
– смотреть телевизор;
– кататься на велосипеде.

**6. Напиши, как скажет друг, если он в свободное время:**
– не слушает музыку, а читает книги;
– не смотрит телевизор, а катается на велосипеде;
– не гуляет с друзьями, а играет в шахматы.

**7. Дополни диалог.**
– ... ?
– Әйе, буш вакытым бар.
– ... .
– Ярый. Мин сиңа реферат язарга булышам.

**8. Дополни диалог.**
– ... ?
– Әйе, спорт белән шөгыльләнәм.
– Сиңа нинди спорт төре ошый?
– ... .

**9. Позови друга (подругу) после уроков пойти:**
– в парк;
– в музей;
– на выставку (күргәзмә).

**10. Посоветуй другу:**
– читать книги;
– заниматься спортом;
– ходить на свежем воздухе.

**11. Узнай у друга о том:**
– был ли он в театре (в музее);
– какой спектакль он смотрел;
– во сколько начинается спектакль (фильм);
– есть ли билеты на спектакль (фильм);
– понравился ли ему спектакль (фильм).

**12. Напиши небольшой рассказ о том, как ты проводишь свободное время.**

## Өлкәннәр һәм кечкенәләр

**1. Переведи.**

Өлкәннәр, кечкенәләр, оныклар, уллар, һәркем, һәрвакыт, яшьтәшләр, тәрбияле, игътибарлы, ярдәмчел, әдәпле, хөрмәт итә.

**2. Дополни диалог.**
– ... ?
– Әбием, бабам, әнием, әтием, абыем бар.
– ... ?
– Әти заводта эшли.
– ... ?
– Токарь булып эшли.

**3. Продолжи диалог.**

– Син өйдә нинди эшләр эшлисең?
– ... .
– Ә ашарга пешерәсеңме?
– ... .

**4. Попроси сестру помочь тебе:**

– помыть посуду;
– убраться в комнате;
– накрыть стол;
– решить задачу.

**5. Попроси брата:**

– сходить в магазин;
– помыть полы;
– накрыть стол.

**6. Дополни диалоги.**

1) – Син өлкәннәрне ничек хөрмәт итәсең?
– ... .
– Мин дә өлкәннәргә һәрвакыт булышам.

2) – ... ?
– Әйе, мин транспортта өлкәннәргә урын бирәм.
– Син транспортта кемнәргә урын бирәсең?
– ... .

**7. Как скажешь о том, что ты:**

– уступаешь место в трамвае дедушке;
– уступаешь место в трамвае старшим?

**8. Попроси разрешения у мамы:**

– пойти в кино с друзьями;
– пойти в гости к друзьям.

**9. Расскажи о том, как ты ухаживаешь за своими бабушками и дедушками.**

## Без Татарстанда яшибез

**1. Переведи.**

Табигать, файда, кояш, болыт, су, ком, таш, үсемлекләр, күл, елга, борынгы, уртача континенталь, зыян, чүп ташлыйлар, агачларны кисәләр, сындыралар, учак ягалар.

**2. Как скажешь о том, что ты:**

– живёшь в Республике Татарстан;
– любишь природу Татарстана;
– знаешь много рек Татарстана;
– знаешь много песен о Татарстане?

**3. Скажи о том, что:**

– Казань – большой и красивый город;
– в Казани много музеев;
– станции казанского метро очень красивые;
– ты хочешь посмотреть исторические места Казани;
– ты хочешь посетить музей М. Горького.

**4. Напиши небольшой рассказ о природе Татарстана.**

# ЭЧТӘЛЕК

7 нче сыйныфта «Татарстан Республикасы дәүләт (татар) теле» фәнен укыту өчен төзелгән «Татар теле» укыту-методик комплекты белән эшләү үзенчәлекләре ........ 3

Календарь-тематик план ........ 7

Ишетеп аңлау күнегүләре ........ 11

Контроль һәм үзконтроль өчен үрнәк биремнәр ........ 30

*Методическое пособие*

**Хайдарова** Роза Закиевна
**Ахметзянова** Гульназ Магсумзяновна
**Гиниятуллина** Лейсан Адиповна

Обучение татарскому языку
в образовательных организациях основного общего образования
с обучением на русском языке

7 класс

Пособие для учителей

Редакторы:
**Ильгизар Закиев,**
**Алсу Низамеева**

Компьютерная вёрстка
**Елены Шараповой**

Подписано в печать 10.08.2025.
Формат 170×205 1/4. Бумага офсетная.
Гарнитура «Arial». Тираж экз. Заказ №

Издательство «Татармультфильм»
420066, г. Казань, пер. Односторонки Гривки, д. 32, помещ. 2

Отпечатано в полном соответствии с качеством
предоставленных материалов в типографии



9 785906 508508

**«Татармультфильм»**